**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью 1 Закона Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по осуществлению государственного контроля (надзора) в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, а также за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной со строительством многоквартирных домов»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 октября 2017 года

## Статья 1

Внести в статью 1 Закона Республики Татарстан от 27 декабря 2007 года № 66-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по осуществлению государственного контроля (надзора) в области долевого строительства многоквартирных домов и (или) иных объектов недвижимости, а также за деятельностью жилищно-строительных кооперативов, связанной со строительством многоквартирных домов» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 12 (II часть); 2010, № 5 (I часть), № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 8 (I часть); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (I часть) следующие изменения:

1) в абзаце тринадцатом слова «, уполномоченного на осуществление государственного кадастрового учета, государственной регистрации прав, ведение Единого государственного реестра недвижимости и предоставление сведений, содержащихся в Едином государственном реестре недвижимости» заменить словами «и его территориальных органов, осуществляющих государственный кадастровый учет, государственную регистрацию прав, ведение Единого государственного реестра недвижимости и предоставление сведений, содержащихся в Едином государственном реестре недвижимости»;

2) в абзаце девятнадцатом слово «граждан» заменить словами «участников долевого строительства»;

3) абзац двадцать третий изложить в следующей редакции:

«направление в правоохранительные органы материалов, связанных с выявлением фактов нарушения обязательных требований, имеющих признаки уголовно наказуемых деяний, для решения вопросов о возбуждении уголовных дел;»;

4) дополнить абзацем следующего содержания:

«размещение в единой информационной системе жилищного строительства информации, указанной в части 5 статьи $23^{3}$ Федерального закона.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
13 ноября 2017 года
№ 82-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) унөченче абзацта “гамәлгә ашыруга вәкаләтле органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы)” сүзләрен “гамәлгә ашыручы органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы) һәм аның территориаль органнарыннан” сүзләренә алмаштырырга;

2) унтугызынчы абзацта “гражданнарның” сүзен “өлешле төзүдә катнашучыларның” сүзләренә алмаштырырга;

3) егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“мәҗбүри таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартырлык гамәлләр кылу билгеләре булган фактлары ачыклануга бәйле материалларны җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен хокук саклау органнарына җибәрү;”;

4) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына Федераль законның $23^3$ статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 13 ноябрь
№ 82-ТРЗ